## ДИДАКТИК УЕН
## “ЯШЕЛЧӘЛӘР ҺӘМ ҖИЛӘК-ҖИМЕШЛӘР”

**Максат:** балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләвен үстерү, җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең исемнәрен, кайда үсүләрен белүне ныгыту; сүз байлыгын арттыру.

**Җиһазлау:** җиләк-җимеш һәм яшелчәләр рәсемнәре Төшерелгән кечкенә карточкалар; сад-бакча һәм бакча рәсемнәре төшерелгән 2 зур карточка.

**Уен барышы:**

Бу уенда 1-2 бала уйный. Балалар яшелчәләрнең һәм җиләк-җимешләрнең кайда үсүе һәм аларның сыйфатлары турында сөйлиләр. Мәсәлән: бу кишер, ул бакчада үсә. Кишер тәмле, баллы.
















